| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2020 г.Зеленодольск № 516

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгының, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасарының, «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисенең, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 658 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте**:

1. 2020 елның 1 октябреннән түбәндәгечә билгеләргә:

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына ай саен 34967 (утыз дүрт мең тугыз йөз алтмыш җиде) сум күләмендә акчалата түләү һәм ай саен 83937 (сиксән өч мең тугыз йөз утыз җиде) сум күләмендә акчалата түләү;

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасарына ай саен 31469 (утыз бер мең алтмыш тугыз) сум күләмендә акчалата түләү һәм ай саен 33929 (утыз өч йөз егерме тугыз) сум күләмендә акчалата түләү;

«Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисенә ай саен 31469 (утыз бер мең алтмыш тугыз) сум күләмендә акчалата түләү һәм 33929 (утыз өч йөз егерме тугыз) сум күләмендә ай саен акчалата түләү;

2. 2020 елның 1 октябреннән ел саен түләнә торган отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгына 34967 (утыз дүрт мең тугыз йөз алтмыш җиде) сум күләмендә;

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасарына 31469 сум (утыз бер мең дүрт йөз алтмыш тугыз) сум күләмендә;

«Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисенә 31469 (утыз бер мең дүрт йөз алтмыш тугыз) сум күләмендә.

3. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен Кушымта нигезендә билгеләргә.

4. Хезмәт өчен түләү фонды төзегәндә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның (бер елга исәпләгәндә) суммасыннан тыш, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәдә билгеләнгән еллык түләүле отпуск һәм матди ярдәм күрсәтелгәндә айлык өстәмә түләүләр, акчалата түләү, премияләр, бер мәртәбә түләнә торган түләүләр өчен акча каралган дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның 1-3 пунктларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тиешле елга тәэмин итү, Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. 2020 елның 1 октябреннән Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 291 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен билгеләү турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы урынбасары** **Э. Р. Кадникова**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы карарына
кушымта

2020 елның 7 сентябре,№ 516

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ

| Муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәренең атамасы | Айлык вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | 34494 |
| Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | 31850 |
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, | 31275 |
| «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы » МУ җитәкчеләре | 31160 |
| «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы »МУ җитәкчеләре урынбасарлары | 28286 |
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе | 28975 |
| Мөстәкыйль бүлек (идарә) начальнигы , Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесе, "Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы" МУ аудиторы» | 23686 |
| Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының мөстәкыйль бүлеге (идарәсе) начальнигы урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары, Зеленодольск муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы киңәшчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе, Зеленодольск | 19547 |

| | |
|---|---|
| муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе киңәшчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты идарәсе составындагы бүлек башлыгы ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең ярдәмчесе, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты составындагы бүлек начальнигы | |
| Бүлек мөдире | 18167 |
| Баш белгеч | 17477 |
| Әйдәп баручы белгеч | 16443 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 14718 |